СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

7 ФЕВРАЛЬ, 1997ел. ҖОМГА

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 14 (8026) | Бәясе билгеләнгәнчә.

## Көн тәртибендә - терлекчелек мәсьәләләре

Соңгы вакытта районда терлекчелек тармагында эшне фән һәм алдынгы тәҗрибә нигезендә оештыру юнәлешендә зур чаралар күрелә. Аерым алганда, сөт терлекчелегендә киләчәктә югары уңышка ирешү өчен сөт ташлаткан сыерларны махсус рацион белән ашату, алардан алынган үрчемне салкында асрау, савым көтүен дә югалтуларсыз механизмга нигезләнгән технология белән карау юнәлешендә шактый эш башкарыла. Бу мәсьәләдә эшне җитди һәм тиз тотучы хуҗалыклар да бар. Күптән түгел «Комбайн» КХАсы базасында тәҗрибә уртаклашу, алга таба бурычларны барлау максатында хуҗалыклар җитәкчеләре, белгечләр катнашында семинар - киңәшмә булып үтте.

Семинар эшен хуҗалыкның икенче бригадасыннан, махсус рацион белән, аерым карала торган сөт ташлаткан сыерлар янынннан башлады. Аннары салкында асрала торган бозауларны, «салкын» читлекләрне карадылар. Икенче бригадада салкын абзарда асрала торган бозауларга игътибар юнәлтелде. Биредә эш ысулы гади һәм тулысынча югалтуларсыз асрау механизмына юнәлгән: электр энергиясеннән файдаланылмый, бозаулар иректә, асларына калын итеп салам җәелгән, шуңа күрә тирес түгүгә дә чыгымнар тотылмый. Нәкъ шундый салкын абзарда малларның көр булуы, йөткермәве, маңгай йоннары да коелмавы, маллар өчен дә, терлекчеләр өчен дә сәламәт микрофлора хөкем сөрүе ассызыкланды. Савым көтүен асрауда да шундый күренеш булуы ачыкланды. Биредә шулай ук малларның асларына калын итеп салам җәелгән, утардан кергәч маллар бәйләнми, саву җайланмалары урнаштырылган (аны җәйгә лагерьга күчерергә мөмкин), азыкны абзарда да, утарда да бирергә була, бер сыер савучы кулы аша 50 сыер үтәргә мөмкин. Өстәвенә, электр энергиясе элеккегегә караганда өч тапкыр азрак тотыла. Кыскача гына әйткәндә, сыер савучы хезмәте дә җиңеләйгән, югалтулар да чикләнгән. Хуҗалыктагылар әйтүенчә, шундый ысул белән эшли башлаганнан бирле сыерлар сөтләрен дә арттырганнар.

Семинар - киңәшмәнең икенче өлеше Әмзә авылы культура йортында дәвам итте. Анда беренче кварталның беренче ае нәтиҗәләренә йомгак ясалды. Район хакимияте башлыгы, халык депутатларының район Советы рәисе Ф.С.Сибагатуллин, гомумән алганда, бу айда район хуҗалыкларында эш күрсәткечләре начар булмавын белдерде һәм терлекчелек продукциясен арттыруда тормыш таләбен аңлап, җиң сызганып эшләүчеләргә рәхмәт сүзен җиткерде. Ай күрсәткечләре буенча тәфсилле анализны район хакимияте башлыгының беренче урынбасары Ю.В.Терентьев ясады (бу хакта газетабызның киләсе саннарында укый алырсыз). Соңыннан Ф.С.Сибагатуллин йомгаклау сүзендә терлекчелек тармагы алдында торган отышлы һәм нәтиҗәле дә югалтуларсыз механизм ысулын гамәлгә ашыру, зоотехния эшен яхшырту, индивидуаль сектордан сөт җыюны, исәп - хисап, отчет мәсьәләләрен җайга салу бурычларына тукталды.

## «ҮЗЕБЕЗ ЭЗЛӘРГӘ, ҮЗЕБЕЗ ТАБАРГА...»

Йөгәнне дә, йөкне дә үз җилкәсенә алган предприятие - оешмалар саны соңгы вакытта күзгә күренеп арта торалар. Гыйнвардан алар арасына Лениногорск шәһәр электр челтәренең Норлат участогы да кушылды. Хәзер ул «Таткоммунэнерго» республика производство берләшмәсенең Норлат шәһәр электр челтәре дип аталучы мөстәкыйль дәүләт предприятиесе итеп үзгәртелде.

- Вәкаләтебез генә түгел, мәшәкатебез дә артты. Үзебезгә эзләргә, табарга, үз көнебез турында үзебез кайгыртырга туры киләчәк, - дип җавап бирде предприятиенең директоры Ә.И.Камалетдинов үзгәреш асылын аңлатуын үтенүебезгә кыска итеп.

## Директор алышынды

Узган җомга көнне «Тәрнәс спирт заводы» дәүләт унитар предприятиесендә гомуми җыелыш булды. Җыелышта предприятие директоры А.М.Воронин вазифаларыннан азат ителде. Предприятие директоры итеп Фәрит Фатыйх улы Җирҗизов сайланды.

Җыелышта «Татспиртпром» берләшмәсе баш инженеры О.М.Тумаков, шулай ук район хакимияте башлыгы урынбасары Ф.Н.Гобәйдуллин катнашты.

## Хезмәтләре белән мактаулылар



Хуҗалыкта яхшы моторист булу зур нәрсә ул, дип саный Хафизов исемендәге КФХА рәисе В.Булатов һәм ассоциация мотористы Камил Хөснуллин турында сөйләп китте:

- Искиткеч әйбәт белгеч, намуслы кеше, үрнәк гаилә башлыгы ул.

Ә Камил ага, чыннан да, мактауларнын теләсә ниндиенә лаек кеше. Хуҗалыкта анын ярдәме тимәгән механизатор сирәктер, мөгаен. Ни өчен дигәндә, тегe яки бу төр техниканың «йөрәге» - моторында чатаклык килеп чыкканда, механизаторлар иң элек аңарга мөрәҗәгать итәләр, чөнки беләләр: Камил агалары моторның гөрелтесе буенча ук «сырхавын» тиз табып, аны «дәвалау» чарасын да күрәчәк. Техника «докторы» Хөснуллин белән машина - тракторлар мәсьәләсендә генә түгел, тормышта килеп туган башка ситуацияләр буенча да киңәш - табыш итүчеләр байтак.

**Рәсемдә: К.Хөснуллин.**

**Н.АЗИЗОВ фотосы.**

*Норлат шәһәр үзидарә Советында*

## УРАМНАРГА - ЯКТАШЛАРЫБЫЗ ИСЕМЕН

Шушы көннәрдә Норлат шәһәр үзидарә Советы шәһәрнең көнбатыш микрорайонын урамнарга бүлеп, аларны исемләү турында карар кабул итте. Шәһәр Советы хәрби интернационалистлар район Советының әлеге микрорайондагы урамнарга ерак Әфган җирендә һәлак булган якташларыбыз исемнәрен бирү турындагы тәкъдимен искә алып эш итте. Әйтик, иң зур урамга **Интернационалистлар** исеме бирелде. Калганнары Әфган сугышында һәлак булган якташларыбыз Миншакир **Бакиров**, Александр **Андронов**, Рәис **һадиев**, Ирек **Сафиуллин**, Иван **Семенов** исемнәрен йөртәчәкләр. Поселоктагы тагы ике урам **Шоссейная** һәм **Симбирская** дип аталды. Якын арада техник инвентарьлаштыру бюросы яңа оештырылган урамнардагы йортларны номерлау белән шөгыльләнсә, күптармаклы җитештерү предприятиесе урам исемнәре һәм йорт номерлары күрсәтелгән аншлаглар әзерләячәк.

## БЕРГӘ БУЛЫРГА ЯЗГАЧ

*Хуҗалыкларда структур үзгәрешләр дәвам итә*

Соңгы вакытта районның агропромышленность комплексындагы кайбер структур үзгәрешләр турында хәбәр иткән идек инде. Берничә хуҗалыкны һәм ит комбинатын ахыр максаты күбрәк итеп дуңгыз ите җитештерү булачак агрофирмага берләштерү, тагын берничә хуҗалыкны бергә кушу күпчелек тарафыннан нигездә гадәти хәл буларак тыныч кабул ителде. Ә менә Югары Норлат белән Түбән Норлатны кушалар икән дигән хәбәр алдан ук зур кызыксыну уятты. Хикмәт бит Кондырча елгасының икесе ике ярына урнашкан, авыллар арасы да кул сузымында гына диярлек булган ике колхозны бер итү турында түгел, ә эш юнәлешләре төрле булган ике хуҗалыкны бер - берсенә «ябыштыру» турында бара иде. Җитмәсә, моннан кырык еллар чамасы элек бу ике хуҗалык бер мәртәбә берләшкәннәр дә иде инде, шуннан икесе дә озак еллар ул чактагы эреләндерелгән «Дружба» колхозы составында тордылар. Аннан инде җитмешенче елларда Югары Норлатта мөгезле эре терлек симертү буенча хуҗалыкара берләшмә оештырылды, сиксәненче еллар ахырында Түбән Норлат та «Кондырча» колхозы булып башка чыкты. Һәм менә кырык еллап вакыт узгач яңадан кушылу.

Яшерен - батырын түгел, һәр ике авыл халкының да үзләренә генә хас горурлыгы, үз авылын һәм хуҗалыгын ярату һәм якын күрү хисе бар. Җыйнак кына мөстәкыйль хуҗалык булып яшәүнең дә тәмен аера беләләр. Шуңа күрә 3 февральдә узган җыелышта ике якның да бергә кушылуның максаты ни булуы, аның нәрсә бирәчәге турында үзләрен кызыксындырган (һәм борчыган да) сорауларга анык җавап ишетми торып кына берсүзсез кул күтәрүен көтәсе дә юк иде. Һәм шулай булды да. Әмма шунысы игътибарга лаек иде, җыелышта сүз сораучыларның барысы да диярлек ,бергә кушылгач хуҗалык итүнең нинди юнәлештә барачагы, моның гомуми эшкә зыян китерү - китермәве, берләштерелгәннән соң авылларның, бигрәк тә Түбән Норлатның социаль проблемалары ничек хәл ителәчәге хакында булды. Аннары ике як та үзләренең моңарчы ирешкәннәре, хезмәт нәтиҗәләре юкка чыкмасмы дип тә борчылдылар төсле. Ни әйтсәң дә, мөгезле эре терлек симертү белән шөгыльләнгән Югары Норлатлылар икътисадый - финанс ягыннан районда иң хәлле хуҗалыкларның берсе саналса, «Кондырча» ассоциациясе икенче ел инде сөт җитештерүдә лидерлар сафында бара. Дөрес, беренчеләренең хәллелеге аларга авылның социаль проблемаларын, беренче чиратта газ кертүне уңышлы башкарып чыгарга мөмкинлек бирде. Ә менә соңгысы Түбән Норлатта ахырына җиткерелмәгән әле. Билгеле, беренчеләренең кайбер проблемаларын район да күтәреште. Инде менә ике хуҗалык бергә кушылгач, ул колачлы мәсьәләләрне уртак көч белән хәл кылырга туры киләчәк. Ә аларны хәл итүне озакка сузарга һич ярамый, чөнки берләштерелгән һәм «Кондырча» дип исемләнгән хуҗалыкның җитәкчесе итеп бертавыштан сайланган Йосыф Әхмәтсафин әйтеп үткәнчә, йортындагы проблемалардан башы каткан кешедән производствода рәтле эш көтү урынсыз. Шуңа да хәзер ике хуҗалык эшчәннәре дә бер йодрык булып (үзләре әйткәнчә, чәчләре чәчкә бәйләнгән бит инде аларның) уртак максатка эшләргә кирәк булачагын ачык аңлап таралыштылар бу җыелыштан. Ә ул максат бүген бер генә - ике авыл халкының да эшкә уңганлыгын, үҗәтлеген бергә кушып, производствоны да бер күзлектән карап оештырып, һәм игенчелектә, һәм терлекчелектә үзләренең моңа кадәр тоткан даннарын саклау гына түгел, тагын да ишәйтү һәм шуның нигезендә калган проблемаларны да бергәләп хәл итү. Җыелышта катнашып чыгыш ясаган район хакимияте башлыгы, халык депутатларының район Советы рәисе Ф.С.Сибагатуллин да болар хакында ачык итеп әйтте.

Җыелышта район авыл хуҗалыгы идарәсе начальнигы Ә.Н.Рәхмәтуллин, район хакимияте аппараты җитәкчесе Ф.М.Галимов катнашты.

***

Узган шимбә көн Киекле крестьян хуҗалыклары ассоциациясе членнарының да гомуми җыелышы булып узды. Җыелыш Ә.Ю.Ганиевның үзен рәислек вазифаларыннан азат итү турындагы үтенечен канәгатьләндерде. Хуҗалык рәисе итеп моңа кадәр «Кондырча» КХА рәисе булып эшләгән Наил Шакир улы Шарапов сайланды.

Җыелышта район хакимияте башлыгы урынбасары - авыл хуҗалыгы һәм азык төлек идарәсе начальнигы Ә.Н.Рәхмәтуллин, хакимият аппараты җитәкчесе Ф.М.Галимов катнашты һәм чыгыш ясады.

# «МӨСТӘКЫЙЛЬЛЕКНЕ САЙЛАУ ХӘЕРЛЕРӘК БУЛЫР»

**29 гыйнвар көнне 53 нче СМУ коллективының отчет җыелышына килгән «Жилстрой» АҖ генераль директоры Ә.Н.Шәвәлиев идарәне АҖннән аерып мөстәкыйль яшәтергә карар кылынуы турында хәбәр итте.**

53 нче төзү - монтаж идарәсенең чирек гасырлык тарихындагы бу кискен структур үзгәрешнең сәбәпләре тирән һәм җитди. Идарәнең яңа начальнигы И.Я.Гайнановның отчет докладыннан ишетелгәнчә, соңгы вакытта, бигрәк тә 1996 ел агымында 53 нче СМУның финанс хәле шәптән булмады: заказчылар башкарылган эшкә үзвакытында түли алмау сәбәпле, СМУның материал белән тәэмин итүчеләр арасында үзара исәп - хисапны өзү мөмкинлеге чикләнде, бюджетка, бюджеттан тыш фондка, коллективка хезмәт хакы өчен бурычлары 3 миллиардка якын җыелды, дебитор бурыч 7 миллиардтан артык, ә кредиторларга аннан тагын 2 миллиардка күбрәк тәшкил итә. Керемнәргә килгәндә, төп эшчәнлек буенча керем бары тик 50 миллион сумга, ә баланс кереме 1 миллиард ярым сумга якын. Бу сумма бурычлар белән чагыштырганда юкка тиң. Шул керемнең зур өлеше салым түләүгә китсә, калган өлеше салымны үзвакытында түләмәгән өчен пеня түләүгә, экологик фондка, бартер килешүләр өчен махсус түләүләргә, дивидендларга һәм башкаларга китә.

Дөрес, башкарылган эш планның 87,6 процентын тәшкил итә , тик шул эшнең зур өлешенә әле һаман акча алынмаган. Ә эш күләме көннән - көн кими, үткән елда СМУ тарихында элек булмаганча кадрлар алмашына һәм эш хакы канәгатьләнерлек булмаганга, ул да вакытында түләнмәгәнгә югары квалификацияле белгечләр, эшчеләр күпләп китәләр.

Югарыдагы мәгълүматлардан күренгәнчә, идарәнең хәле кризиста, һәм кичекмәстән хәлиткеч чаралар күрмичә, уңай якка үзгәрешләр булмаячак. «Жилстрой» АҖнең генераль директоры Ә.Шәвәлиев (трест Әлмәт шәһәрендә) коллектив алдында чыгышын нәкъ шул фикердән башлады. Аның әйтүенчә, идарәнең язмышын хәл итү мәсьәләсе үткән ел башында ук көн тәртибендә булган: трест эшче урыннарны кыскартыргамы, әллә түләүгә сәләтле заказчылар табаргамы, ягъни эш күләмен эзләүне дәвам итәргәме дигән ике юл чатында торып кала, һәм бер елга икенчесен сайлый. Бер еллык тәҗрибә бу юлның базар шартларында яшәүчән, эффектив түгеллеген, эшчеләрнең тормыш - көнкүреш шартларын яхшыртмавын тагын бер кат ачыклый. Гомумән, республикада зур трестлар аз кала бара, бүген көн үзәгендә аларны вакլап, аерым предприятиеләрнең аяк - кулларын чишеп мөстәкыйль, бәйсез рәвештә үз язмышларын үз кулларына тапшыру күздә тотыла, ди генераль директор. Чират Норлат СМУсына да җитә. Ә Шәвәлиев бу процессны, гади итеп, ата кешенең үсеп җитлеккән улын башка чыгаруга тиңли: улы үз көнен үзе күрә, һәр тиен өчен атасы каршына йөгерми, мөстәкыйль рәвештә эшләп таба, тик туганлык җепләре өзелми. Соңгысын рәсми телгә күчергәндә, «Жилстрой» АҖ 53 нче СМУның, өлешкә керү нигезендә, учредителе булып чыгачак. Бу мәсьәләләр барысы да Дәүләт мөлкәт комитеты, район хакимияте һәм төп заказчы «Норлатнефть» НГДУсы администрациясе белән килешенгән һәм, аның фикеренчә, соңгы икесе дә шундый ук нигездә учредитель ролен алачаклар булырга күренә. Хәер,бу әле алда ачыкланачак мәсьәлә.

«Мөстәкыйльлек эшкә намуслы карашлы, фидакарь кешеләрне куркытмаска тиеш,- ди генераль директор. - Яңа шартларда эшләячәк оешмага күчү һәркемнең үз ихтыярында». Җитәкчелек максатчан кыскартулар көтелмәвен хәбәр итсә дә, һәрхәлдә көймәдә калу өчен бик көчле ишәргә туры киләчәк. Эшчеләр контракт нигезендә эшләячәк. Бу ысул үз чиратында җаваплылык тудыра, контракт шартларын үтәмәүчеләр, әлбәттә, төшеп кала һәм башка эш урыны эзләргә мәҗбүр була. Ләкин соңгысы, тулаем алганда, СМУ эшчеләренә кагылмый дияргә мөмкин. Үзләре әйтүенчә, ярты Норлатны төзегән бу идарә сан ягыннан да, сыйфат ягыннан да әлегә сынатмады. Бүген дә эш кенә булсын аларга һәм тиешенчә түләнсен генә. Ә менә ярты елга якын түләнмәгән хезмәт хакын тресттан аерылгач кем түләр? Бу җыелышта эшчеләрнең генераль директор Ә.Шәвәлиевка биргән беренче сораулары иде. Җавап тотучы идарәнең хезмәт хакы буенча, җирле бюджеттан кала республика, Россия Федерациясе бюджетларына, бюджеттан тыш фондларга салым һәм башка бурычларын үз өстенә алырга вәгъдә бирде. Кыскасы, ул яңача яшәү һәм эшләү бурычларсыз башланырга тиеш, дигән фикерне җиткерде.

Эшчеләрне фатир бирү мәсьәләсе дә борчый. Әмма бу сорауга тынычландыргыч җавап ишетелмәде: бүген базар икътисады фатирны бары тик сатып алу шарты гына тудыра. Инде йорт салырга ниятләүчеләр дә бары тик беренчел капиталны керткәч кенә аңа өметләнә алалар.

- СМУның элекке начальнигына салынган «йорт - музей» безнең идарәгә нинди чыгымнар китерде?

Генераль директорның бу сорауга җавабы конкрет булмаса да, ачык һәм аңлаешлы яңгырады: әлеге йорт төзү чыгымнарын үз өстенә Чаллы Башындагы ниндидер ассоциация алган булган, әмма бүгенге көнгә кадәр ул бер тиен дә түләмәгән, билгеле вакытка кадәр шулай дәвам итсә, йорт сатылачак, диде ул.

Җыелыш ике дистә елын 53 нче төзү - монтаж идарәсенә биргән юбиляр Людмила Николаевна Яцкованы хөрмәтләп пенсиягә озату белән тәмамланды.

Соңында идарә начальнигы белән әңгәмәдә структур үзгәрешнең коллективның ары таба тормышында чагылышы белән кызыксындык. Элеккечә, түләргә сәләтле заказчылар табу кыен булмасмы?

- Һич юк, коллективның заказчылар каршында абруе зур, чөнки төпле исәпле заказчыны иң элек тизлек түгел, ә сыйфат кызыксындыра. Заказчы белән мөнәсәбәтләр үзара килешү нигезендә төзеләчәк. Ә без заказчы таләпләрен үтәргә, эзләнергә, төзелештә яңа төр материаллар кулланырга тиешлегебезне аңлыйбыз. Аннары эш төзелешкә генә терәлеп калмаячак: яхшы яшәү өчен коммерция белән дә, бакчачылык белән дә шөгыльләнергә туры киләчәк,- ди ул. - Кыенлыкларга карамастан, безнең кәеф оптимистларча.

**Ф.ЗЫЯТДИНОВА.**

**P.S. Материал газетага әзерләнгәннән соң, Әлмәттә «Жилстрой» АҖ акционерлар җыелышында 53 нче СМУның статусы һәм исеме үзгәртелүе ачыкланды. Акционерлар бертавыштан Норлатның 53 нче СМУсын аеруны яклап, аңа чикле җаваплылыктагы җәмгыять статусы бирәләр. Эшчеләр үтенече буенча идарә исеме элеккечә калдырыла: ул «53 нче СМУ» ОООсы дип аталачак.**

# САЛЫМ ПОЛИЦИЯСЕ ЭШТӘ

29 гыйнварда Татарстан Республикасы Салым полициясендә 1996 ел йомгаклары буенча журналистлар өчен брифинг булды. Массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре белән Татарстан Республикасы Салым полициясенең федераль хезмәт идарәсе башлыгы Сергей Машин һәм Татарстан Республикасы Дәүләт салым инспекциясе башлыгы Шамил Бадамшин очрашты.

Республикадагы предприятиеләрнең һәм оешмаларның икътисадый хәле катлаулы булуга карамастан, җыелма бюджетның керем өлеше 9 триллион 408 миллиард сум тәшкил итте. Бу - 1995 елгыдан 1,5 тапкыр күбрәк. Бюджетка керемнәрнең 80 процентын салым бирде. Түләнеп бетмәгән акча 1996 ел башындагы 40 проценттан ел ахырына 16,8 процентка кадәр кимеде. Спирт һәм ликер - аракы продукциясен җитештерүче предприятиеләрдә салым постларын булдыру акцизларны 1995 елдагыдан 2,3 тапкыр күбрәк алу мөмкинлеге бирде. Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты инициативасы белән банктан тыш акчалар белән көрәш чаралары күрелде.

Салымнан яшерелгән керемнәрне кайтару өчен башкарылган документаль тикшерүләр узган ел Татарстан бюджетына 362584 миллион сумны өстәп кайтарырга мөмкинлек бирде. 1996 елда бюджетны тулыландырган салымнарның гомуми суммасыннан 42 процентын чынлыкта «көч куллану» чаралары белән алырга туры килде. Кайбер предприятиеләрнең милке кулга алынды.

Татарстан Республикасы Салым полициясе җитәкчелеге, 1997 елда салымнарны тулысынча җыюга юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыру дәвам иттереләчәк, дип ышандырды. Моннан тыш Министрлар Кабинеты һәм Салым полициясенең уртак карары белән салым түләмәүчеләргә карата күрелә торган чараларны кискенләштерү күздә тотыла.



Котельня җайланмасы операторы булып Рушат өченче кышын эшли инде. Кулдашы Тәлгать Ахунҗанов белән терлекчелек комплексындагы малларны кайнар су, аш белән даими тәэмин итеп тору өчен көчләрен кызганмыйлар алар. Кышлату чорында маллардан продукция алу аларның да намуслы хезмәтенә бәйләнгән бит. Җәй җиткәч, Рушат янә техника тирәсендә булачак. Узган ел да ул КСК - 100 азык җыю комбайнында ярдәмче булып эшләде, үзе турында әйбәт фикер уятты.

Рәсемдә: «Чирмешән» КХАсыннан Р.Хәлиуллин.

**Н.АЗИЗОВ фотосы**

*Шәхси хуҗалык - өстәмә чыганак*

# Активрак эшләргә туры килер

Җирле үзидарә Советы рәисе булып әле беренче генә чакырылыш эшлим мин. Баштан ук үзем өчен төп хакыйкатьне үзләштердем: утырышлар саны белән түгел, ә ахыргы нәтиҗә белән үлчәнә хезмәт. Халыктан сөт сатып алу белән дә шулай килеп чыга. Сәләнгешлеләр, хәтерләвемчә, бу эштә һичкайчан соңгылар рәтендә булмадылар, аны сатып алуны яхшы итеп оештыр, контрольне йомшартма һәм, иң мөһиме, тапшырылган продукция өчен халык белән үзвакытында исәп - хисап кына ясa. Шөкер, хәзер түләү мәсьәләсе җайга салынды, кешеләр үзләренә тиешле акчаны да айныкын - айга алып баралар. Ә 2 - 3 ел элек сөт - май комбинаты акчаны колхоз кассасына күчерә иде дә, аның сөт тапшыручыларга кайчан барып җиткәнен дә күзаллау мөмкин түгел иде. Хуҗалыкта чыгымнар азмыни? «Ак барс» вексельләре акча түгел бит, кибеттә аңа товар бирсәләр дә, «тере», үз йортың ярдәмендә эшләп алынганнары һәр кешегә бик кирәк. - Ут, газ өчен түлисе, шәһәрдәге балаларга булышасы, базардан әйберләр сатып аласы була.

Безнең ике авыл - Сәләнгеш белән Зүзәйдә 183 сыер исәпләнә. Кайбер гаиләләр икешәрне дә асрыйлар. Узган ел без сөт - май комбинатына 662 центнер сөт озаттык, бу планлаштырылганнан 132 центнерга күбрәк булды. Һәр сыерга сатып алынган сөт 362 килограмм булды. Сөтне без ел буе җыябыз, моны ничек оештырабыз соң без? Гыйнварда ук йорт саен йөреп чыгам һәм һәр хуҗалыкның мөмкинлекләрен ачыклыйм. Сөт сатып алу барышын даими контрольдә тотарга кирәк, вакытны кулдан ычкындырсаң, ул ахыргы нәтиҗәдә дә бик тиз сизелә. Ә сөтне бездә менә инде икенче ел Александр Васильевич Павлухин җыя. Ул үзе пенсиядә инде, әмма безнең үтенечебезне кире какмады. Иртән иртүк арбалы Т - 16 тракторы белән ул йорт буенча йөри һәм сәгать 8ләрдә сөт җыю машинасы сөтне комбинатка алып китә. Әлегә көн саен 130 - 160 килограмм тапшырабыз, ә җәен, билгеле, күбрәк - 320 - 350 килограмм. Майлылыгын да даими контрольдә тотабыз. Бу эштә безгә «Заветы Ильича» ассоциациясе лаборанты Александра Михайловна Осокина ярдәм итә.

Узган 1996 нчы елда безнең сөт җыючыбыз А.Павлухинның эш нәтиҗәсе район буенча өченче булды. Аның хезмәте авыл хуҗалыгы алдынгылары слетында да билгеләп үтелде. Александр Николаевич Осокин исеме исә иң актив сөт тапшыручылар исемлегендә аталды. Ул ел дәвамында 2950 килограмм сөт сатты. Бу да иң яхшы күрсәткечләрнең берсе. Аларның икесенең дә кыйммәтле бүләкләр белән бүләкләнүләре безнең өчен дә сөенечле булды.

1997 нче елга сөт сатып алу буенча задание тагын да артыграк, димәк, тагын да активрак эшләргә туры киләчәк. Авыл халкы, тагын да күбрәк сыер асрар иде дә, аның бит мәшәкате дә зур. Терлек азыгы хәзерләү дә авыр - болынлыклардан кала, бакчаларыбызда үлән - люцерна, костер чәчәбез. Ә бәрәңге утырту өчен участокларны ассоциация үз кырыннан бүлә.

Әйе, шәхси йорт - продукция җитештерү өчен өстәмә һәм, мин әйтер идем, җитди резерв. Әмма гади авыл эшчесенә һәрчак ярдәм итәргә, аның өлешен гадел бәяләргә кирәк. Шул вакытта аның нәтиҗәсе дә зуррак булачак.

**Н.ИСАЕВА,**
**Сәләнгеш җирле үзидарә Советы рәисе.**

# Яшелчәчеләр өчен ай календаре

| Культуралар исеме | Февраль | Март | Апрель | Май | Июнь | Июль | Август | Сентябрь | Октябрь | Ноябрь |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | **Аеруча уңайлы көннәр** | | | | | | |
| Кузаклылар | - | - | 20,21 | 18-21 | 14-18 | - | - | - | - | - |
| Бәрәңге | - | - | 24-28 | 23-25 | 22 | - | - | - | - | - |
| Суган | 27,28 | 1,26-30 | 22-26 | 20-24 | 16,20 | 14-17 | 11-14 | 10 | - | - |
| Кишер | - | - | 23-24 | - | 25-26 | - | - | - | 17,18,21,22 | 17,19 |
| Кыяр | 8,9 | - | 8,9 | 10,11 | 6-8 | - | 10,11 | 6-8 | 3-5 | 1 |
| Татлы борыч | - | - | 22 | 20,21 | 16-20 | - | - | - | - | - |
| Петрушка (сабагы өчен) | 8,9 | - | 8,9 | 10,11 | 6-8 | 11,12 | 7-11 | 4-8 | 3-5 | 1 |
| Петрушка һәм селдерей (тамырлары өчен) | - | - | 24 | - | 25,26 | - | - | - | 21,22 | 17-19 |
| Шалкан, редис,гәрәнкә | 25-28 | 1,25,28,31 | 24,27,28 | 24-26 | 22,25-26 | 22-23 | 19,20,23,24 | 19,20 | - | - |
| Салат, кәбестә | 8,9,12,13 | 12,13 | 8,9,13,14 | 10,11 | 6-8 | 11,12 | 7-11 | 4-8 | 3-5 | 1 |
| Сельдерей, шпинат | 8,9 | - | 8,9 | 10,11 | 6-8 | - | 10,11 | 6-8 | 3-5 | 1 |
| Чөгендер | 1,4,5,25-28 | 4,5,25-29,31 | 1,4,5,24,27,28 | 2,3,24-26,29,30 | 22,25-26 | - | - | 21,22,28-30 | 17-19,24-29 | - |
| Помидор | 17-19 | 16-18 | 22 | 20,21 | 16-18 | 14,15 | 11 | 15,16 | 13,14 | 9,10 |
| Кабак, кабачки | - | - | 20-22 | 17-21 | 14-18 | - | - | - | - | - |
| Сарымсак | - | - | - | 20,21 | 16-20 | - | - | 6-10 | 3-7 | 1-4 |
| | | | | **Уңайсыз көннәр** | | | | | | |
| | 6-8,19-21 | 6-9,19,20 | 2,3,6-8, 15-17,29,30 | 1,6,7, 12-14,26-28 | 4-6,9, 10,23,24 | 1-8,20, 21,29,30 | 2-4,17,18,25, 26,29-31 | 1,2,13,14, 21-23,26-28 | 1,2,10-12, 18-20,23-25,30 | 7,8,15,16, 19-21,29,30 |

Әлбәттә, яшелчә культураларын һава шартларына һәм башка сәбәпләргә карап төзәтмәләр кертеп бүтән көннәрдә дә чәчәргә һәм утыртырга мөмкин. **(«Казанское время»дан).**

# «Милта» белән үзебездә дәвалыйлар

*«Газетаның 18 гыйнвар санында Норлатта Санкт-Петербургтан лазер терапиясе белән дәвалаучы табиб килүе, бер кабул ителү өчен 40 мең сум түләргә һәм 7 - 10 тапкыр килергә кирәклеге турында укыдым. Андый аппарат Иске Чаллы шифаханәсендә дә бар бит, дәвалау да бушлай. Язгыз әле шул турыда, кеше белеп торсын... »*

**Редакциягә шундый тәкъдим белән шалтырату булганнан соң без Иске Чаллы участок шифаханәсе баш табибы, Татарстан Республикасының атказанган табибы Аркадий Леонтьевич Клементьевка мөрәҗәгать иттек. Ул менә нәрсәләр сөйләде:**

- Магнитлы - инфракызыл - лазер дәвалау ысулы бездә ярты ел кулланыла инде. Үзебездә чыккан «Милта» аппаратын без Мәскәүдән сатып алдык. Ул күп кенә авыруларны, шул исәптән умырткалык һәм буыннар, колак, тамак авыруларын, пешү, сынуларны, трофик язваны, бронхитны, энурезны һәм башка авыруларны дәвалауда кулланыла. Дәвалауның башка органнарга тискәре тәэсире юк. Шул вакыт эчендә бездә 22 кеше дәваланды инде. Гадәттә 3 - 11 сеанстан соң уңай нәтиҗә күренә. Мисал өчен соңгы вакытта өч баланы энурездан котылдыруыбызны да әйтергә була.

Кабинет иртәнге 9дан көндезге 3 кә кадәр эшли, безнең шифаханәнең табибы билгеләмәсе буенча дәвалауны тәҗрибәле медицина хезмәткәре үткәрә.

Икенче ел инде без галатерапия алымында (тоз аэрозоле белән дәвалау) кулланабыз. Ул бронхит, пневмония һәм башка авыруларны профилактикалау һәм дәвалауда уңай нәтиҗә бирә.

# Котлыйбыз!

*Киекле авылында яшәүче кадерле әтиебез, бабабыз **Әнвәр Зәйнетдин улы Гыйләҗетдиновка** 6 нчы февральдә 60 яшь тулды. Аны олы юбилее белән чын күңелдән тәбрик итәбез, саулык - сәламәтлек, бәхет - шатлыклар, кайгы - хәсрәтсез көннәр, балаларының игелеген күреп, һәрвакыттагыча шат күңелле булып, әниебез белән озак яшәвегезне телибез.*

*Озын гомер бирсен ходай дибез,*
*Кояш сиңа бирсен яктылык.*
*Балаларың гына түгел, оныкларың*
*Китерсеннәр сиңа яхшылык.*



***Тормыш иптәше, кызлары кияүләре, оныклары.***

## Рәхмәттән башка сүзебез юк

Чирне беркем дә көтеп алмый. Әгәр дә ул иң якын, кадерле кешеңә килсә, кайгың чиксез, әлбәттә. Безнең гаиләбездә нәкъ шундый хәл килеп чыкты. Көтмәгәндә әтиебез каты авырып китте.

Безнең өчен җир йөзендә иң кадерле кешебез - әтиебезгә беренче ярдәм кулы сузган, барлык тырышлыкларын куйган, яңадан яшәү бүләк иткән Иске Чаллы участок шифаханәсе баш врачы Клементьев Аркадий Леонтьевичка, район үзәк шифаханәсенең реанимация һәм хирургия бүлеге врачларына, барлык шәфкать туташларына олы рәхмәтебезне белдерәбез. Аларның авыр һәм мактаулы эшләрендә зур уңышлар телибез.

**Уразгильдиевлар гаиләсе.**
**Кизләү авылы.**




## Королевага кунакка шобага салып

Британия королевасы Елизавета II гаиләсе үзләренең «алтын туен» бик зурлап билгеләп үтәргә җыена. Ул, әле тәхеткә варис булмаган чакта ук, 1947 елда принц Филипка кияүгә чыга. Алар тантаналы мәҗлескә шул елны никахлашкан 4 мең пар кешене чакырырга җыена. Букенгем сарае бакчасында үтәчәк кабул итү мәҗлесенә кемнәрне чакыру мәсьәләсен хәл итү җиңел түгел, чөнки бу елны 100 мең никах теркәлгән булган. Димәк, кунакларны шобага салу юлы белән сайларга туры киләчәк.

Прибор гадәти күзлек савытына охшаган.Хатын - кыз аны һәркөнне иртән ачуга, кечкенә дисплейда кызыл,яшел һәм сары утларныңберсе яна.

Кызылы - бу тәүлектә секс белән шөгыльләнмәскә кирәклекне искәртә, яшел лампочка янса, тәүлек буе хатын балага узмаячак,сары ут - компьютерга өстәмә тест кирәклеген әйтә. Прибор бу «серне» сидек анализы буенча ачыклый.

## Шикәргә һәйкәл

Мондыйһәйкәл моннан 10 ел элек Чехиянең Дачице шәһәрендә куелган. Ул таш пьедесталга куелган бер шакмак шикәр рәвешендә һәм өч метр биеклегендә.

Һәйкәл куелуның сәбәбе дә бар: 1843 елда нәкъ менә шушы шәһәрдә чех һөнәрчесе Якуб Христоф Рад шакмаклы шикәр ясау ысулын уйлап тапкан.

## Әби игез бала тапкан

Ана һәм баланы саклау буенча Урал фәнни - тикшеренү институты 47 яшьлек ханымның игез бала тудыруы турында сирәк очракны терки. Мондый хәл ун елга бер булгалый икән. Әмма бу балаларның анасына да, табибларга да шатлык китермәгән. Инде оныклары булган әлеге хатын, игезәк улларын бала тудыру йортында калдырып, Белояр районына, өенә кайтып киткән. Янәсе, ул бала көтмәгән, хатын - кызлар консультациясе аның балага узуы турында диагнозны вакытында куймаган. Көмәнле булуы ачыкланганда, инде аборт ясарга соң булган. Өстәвенә үзе - эшсез, ә ире пенсионер икән...

## Машина каракларына «капкын»

Машина каракларына каршы хәзер нинди генә чаралар күрелми дә, нинди генә җайланмалар уйлап тапмыйлар. XXI гасырга аяк басканда автомобиль хуҗаларына химиклар ярдәмгә килә. Алар машинага - күренми торган урынга аэрозоль баллоны яшереп куярга һәм аны автомобиль сигнализациясенә тоташтырырга киңәш итәләр. Чит кеше аны - моны абайламыйча гына автомобильне кабыза икән, баллон аэрозоль төтене чыгара башлый. Карак йөткерә - төчкерә качарга мәҗбүр була. Нәтиҗәсен киләчәк күрсәтер.

## Светофор... балага узудан саклый

Американың бер төркем галимнәре яңа «революцион» саклану чарасы уйлап табуларын игълан иттеләр. Аның ничек тәэсир итүен галимнәр үзләре генә белә, әмма «светофор»ның, югары технологияле булып, электроника белән эшләвен раслыйлар.

## Ирләр һәм хатын - кызларниләр турында сөйләшә?

Кайбер хатын - кызлар сөйләшә дә сөйләшә, аларны һич туктатып булмый. Америка психологлары үткәргән тикшерүләрдән күренгәнчә, бу мәсьәләдә ирләр дә калышмый икән. Шунысы кызык, ирләр һәм хатын - кызлар сөйләшүенең 16 проценты сексками багышлана, аннан соң 12 проценты уртак танышлар турында була, ягъни ләчтит сатуга китә.

**(«Мәдәни җомга»дан).**

# Белдерүләр

## Сатабыз

**1979 елгы, ак төстәге ВАЗ - 2101**. Тел.: 2 - 28 - 99 (кичке 5 тән соң).

***

**Шәһәр уртасында бер бүлмәле фатир.** Тел.: 5 - 25 - 35.

***

**ВАЗ - 21011.** Адрес: Мир ур., 60 - 1 (теләсә кайчан).

***

**Райпоның хәзерләүләр конторасы әйбәт хәлдәге УАЗ - 469 машинасын**. Адрес: Куйбышев ур., 98, тел.: 2 - 29 - 56.

***

## Алмаштырабыз яки сатабыз

**Норлаттагы шәхси йортны - яңа ВАЗга яки сатам.** Тел.: 5 - 25 - 96.

## Эшкә чакырабыз

Чикләнгән җаваплылыктагы «Татнефтедор» оешмасының Норлат автомобиль юллары идарәсенә ашыгыч төстә:
стажлы автокран машинисты,
стажлы дизель двигателе машинисты (хезмәткә түләү вакыт исәбеннән - премиаль),
тәҗрибәле программалаучы (килешү буенча) кирәк.


БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**
МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

**Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның сишәмбе, җомга көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы,19.**

**Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

***Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.***

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2071 данә. Заказ N 5133.